**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсен Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты итеп үзгәртеп кору турында

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары системасын камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге 52-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы, «Аучылык турында һәм аучылык ресурсларын саклау турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 33 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсен Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты итеп үзгәртеп корырга.

2. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенең, шул исәптән төзелгән килешүләрдән һәм шартнамәләрдән килеп чыккан йөкләмәләр буенча да, хокукый дәвамчысы булып тора дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының структурасын расларга (кушымтада бирелә).

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсен Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты итеп үзгәртеп кору белән бәйле чаралар комплексын законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәне эшләргә һәм расларга;

Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты хезмәткәрләренең чик санын Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгыннан кайбер штат берәмлекләрен тапшыруны исәпкә алып расларга һәм «2017 елга һәм 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2016 елның 28 ноябрендәге 93-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә аларның эшчәнлеген финанслауга ассигнованиеләр күләмен билгеләргә»;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм башка хезмәткәрләргә Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсен Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты итеп үзгәртеп кору сәбәпле алар эштән җибәрелгән очракта, гарантияләр һәм компенсацияләрне бирүне законнар нигезендә тәэмин итәргә;

бирелгән субвенцияләрнең тотылуы турында, алар билгеләнгән булса, максат итеп куеп фаразланган күрсәткечләргә ирешү турында квартал саен хисап, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан хайваннар дөньясы объектларын, су биологик ресурсларын саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә, шулай ук аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә үзләренә тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен (алга таба – Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләре) үтәү мәсьәләләре буенча кабул ителгән норматив хокукый актлар нөсхәләрен, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләре тулысынча үтәлүен һәм аның сыйфатын контрольдә тоту һәм күзәтчелек итү өчен кирәкле башка документларны һәм мәгълүматларны тиешле федераль башкарма хакимият органнарына вакытында тапшыруны тәэмин итәргә;

үзенең актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

5. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1215 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 29 гыйнварындагы ПУ-80 номерлы, 2014 елның 10 февралендәге ПУ-132 номерлы, 2014 елның 5 мартындагы ПУ-244 номерлы, 2014 елның 20 мартындагы ПУ-286 номерлы, 2014 елның 19 апрелендәге ПУ-405 номерлы, 2014 елның 26 апрелендәге ПУ-435 номерлы, 2014 елның 2 июлендәге ПУ-636 номерлы, 2014 елның 12 сентябрендәге ПУ-854 номерлы, 2014 елның 28 ноябрендәге ПУ-1091 номерлы, 2014 елның 5 декабрендәге ПУ-1107 номерлы, 2015 елның 16 мартындагы ПУ-289 номерлы, 2015 елның 18 мартындагы ПУ-294 номерлы, 2015 елның 25 мартындагы ПУ-367 номерлы, 2015 елның

17 июнендәге ПУ-562 номерлы, 2015 елның 26 июнендәге ПУ-602 номерлы, 2015 елның 29 июлендәге ПУ-680 номерлы, 2015 елның 10 сентябрендәге ПУ-850 номерлы, 2015 елның 24 сентябрендәге ПУ-892 номерлы, 2015 елның 17 октябрендәге ПУ-995 номерлы, 2016 елның 6 апрелендәге ПУ-331 номерлы, 2016 елның 19 апрелендәге ПУ-366 номерлы, 2016 елның 31 маендагы ПУ-491 номерлы, 2016 елның 6 декабрендәге ПУ-1075 номерлы, 2016 елның 23 декабрендәге ПУ-1192 номерлы, 2016 елның 26 декабрендәге ПУ-1228 номерлы, 2017 елның 15 февралендәге ПУ-143 номерлы, 2017 елның 27 апрелендәге ПУ-345 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-456 номерлы, 2017 елның 3 июлендәге ПУ-598 номерлы, 2017 елның 29 августындагы ПУ-773 номерлы һәм 2017 елның 9 сентябрендәге ПУ-804 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 25 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «25 | Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы | 51»; |

б) 36 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «36 | Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты, | 42 |
| | шул исәптән: | |
| | федераль бюджет акчалары хисабына финансланучы вазыйфалар | 19 |
| | Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына финансланучы вазыйфалар | 23». |

6. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасы турында» 2015 елның 25 сентябрендәге ПУ-899 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 31 маендагы ПУ-491 номерлы һәм 2017 елның 2 августындагы ПУ-662 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «Татарстан Республикасы Дәүләт комитетлары» дигән III кисәктә «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты» сүзләрен өстәргә;

б) «Республиканың башка башкарма хакимият органнары (Татарстан Республикасы ведомстволары)» дигән IV кисәктән «Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе» сүзләрен төшереп калдырырга.

7. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте составына керүче вазыйфаи затлар исемлеге турында» 2015 елның 25 сентябрендәге ПУ-900 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 22 ноябрендәге ПУ-1122 номерлы, 2016 елның 31 маендагы

ПУ-491 номерлы һәм 2017 елның 29 августындагы ПУ-773 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте составына керүче вазыйфаи затлар исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе» сүзләреннән соң «Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе» сүзләрен өстәргә;

б) «Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе башлыгы» сүзләрен төшереп калдырырга.

8. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе турында» 2007 елның 31 декабрендәге ПУ-721 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе структурасына үзгәреш кертү турында» 2012 елның 17 апрелендәге ПУ-259 номерлы Указы.

9. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 06 октябрь
№ ПУ-890

Татарстан Республикасы
Президентының
2017 елның «_06_» октябрендәге
ПУ-_890_ номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасының**
**Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты структурасы**

Рәис

- Рәис урынбасары
  - Хайваннар, үсемлекләр дөньясы өлкәсендә һәм аеруча саклана торган табигать территорияләрендә дәүләт күзәтчелеге идарәсе
    - Административ һәм суд практикасы бүлеге
    - Хайваннар, үсемлекләр дөньясы өлкәсендә һәм аеруча саклана торган табигать территорияләрендә дәүләт күзәтчелеге буенча район (районара) бүлекләр*
    - Биологик төрлелек торышына дәүләт күзәтчелеге бүлеге
  - Идел-Кама дәүләт табигать биосфера тыюлыгының саклау зонасы бүлеге
  - Җыелма-аналитика секторы
- Рәис урынбасары
  - Хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын саклау идарәсе
    - Хайваннар дөньясын мониторинглау бүлеге
    - Биологик төрлелек бүлеге
    - Төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать заказниклары администрацияләре**
  - Су биологик ресурслары бүлеге
  - Гомуми бүлек
- Рәис ярдәмчесе
- Финанс исәбе һәм дәүләт сатып алулары бүлеге
- Хокукый эш буенча әйдәүче киңәшче
- Дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы
- Мобилизация эше буенча белгеч

*Әгерҗе, Азнакай, Аксубай, Актаныш һәм Минзәлә, Алексеевск, Әлки, Әлмәт, Апас, Арча, Әтнә һәм Биектау, Баулы, Балтач, Бөгелмә һәм Ютазы, Буа һәм Чүпрәле, Югары Ослан, Алабуга, Зәй, Зеленодольск, Кайбыч, Кама Тамагы, Кукмара, Лаеш, Лениногорск, Мамадыш, Менделеевск, Мөслим, Түбән Кама, Яңа Чишмә, Нурлат, Питрәч, Балык Бистәсе, Саба, Сарман, Спас, Тәтеш, Тукай, Теләче, Чирмешән, Чистай.
** «Ашыт», «Балтач», «Долгая Поляна», «Зөя буйлары», «Кичке Таң», «Свияжск», «Спас», А.И. Щеповских исемендәге «Степной», «Чатыр-Тау», «Чистые Луга», «Чулпан».

---